**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«30»июль 2019 нчы ел** **№ 108**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге "Җир салымы турында»гы 53 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге «Җир салымы турында" гы 53 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир участокларына, шулай ук «Гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,23%;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә, ләкин 2020 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61 нче йорт,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге" башлыгы, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге" Советы рәисе** **Х.Х. Ибәтов**